# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ

# К А Р А Р

21.11.2016 № 103

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге территориясендә 2016 елның 20 ноябрендәге җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22 статьясы, «җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 55,56 статьялары нигезендә Арча районы территориаль сайлау комиссиясе участок комиссияләренең тавыш бирү нәтиҗәләре турында беренче нөсхәсе мәгълүматлары нигезендә җирле референдум нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча беркетмә төзеде:

“2017 елда Урта Курса авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 200 сум күләмендә (түләү күләме 100 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, 90 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

- Авылларда юлларны төзекләндерү (вак таш) җәю:

- Югары Курса ав.

А. Алиш ур., 8дән 11гә кадәр,

А. Алиш ур., 4дән 23кә кадәр Школьная ур.;

- Урта Курса ав.

Гагарин ур., 1 йорт, Тукай ур., 11 йорт;

- Сарай-Чокырча ав.

М. Җәлил ур., 8дән 16га кадәр;

- Түбән Курса ав.

Пушкин ур., 1а йорттан алып 27 йортка кадәрАерым мәсьәләләр буенча экономия булганда авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны референдумда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга”.

Референдум нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлануга 752 референдумда катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә референдумда катнашучылар саны-688, бу 91,49% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 682 референдумда катнашучы тавыш бирде, бу 99,13% тәшкил итә; «Юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 6 кеше тавыш бирде, бу 0,87% тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Арча районы территориаль сайлау комиссиясе карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны узган, референдум нәтиҗәләре - гамәлдә дип танырга.

2. “2017 елда Урта Курса авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 200 сум күләмендә (түләү күләме 100 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, 90 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

- Авылларда юлларны төзекләндерү (вак таш) җәю:

- Югары Курса ав.

А. Алиш ур., 8дән 11гә кадәр,

А. Алиш ур., 4дән 23кә кадәр Школьная ур.;

- Урта Курса ав.

Гагарин ур., 1 йорт, Тукай ур., 11 йорт;

- Сарай-Чокырча ав.

М. Җәлил ур., 8дән 16га кадәр;

- Түбән Курса ав.

Пушкин ур., 1а йорттан алып 27 йортка кадәрАерым мәсьәләләр буенча экономия булганда авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны референдумда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга”.

соравы буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3.Җирле референдум нәтиҗәләрен «Арча хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http:pravo.tatarstan.ru. http:pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе рәисе Б. И. Кадыйров

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе секретаре Л. И. Нурмиева